| СОВЕТ РУССКО-АЗЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РУС ӘҖИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2026 елның 29 июле** Рус Әҗиле ав. **№38**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 24 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, техник хаталарны бетерү максатларында, Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге Советының 2026 елның 08 июнендәге 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә (Рус Әҗиле авыл җирлеге Советының 2026 елның 16 июнендәге 36 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 6 өлешендә «статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында» сүзләрен «әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында» сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. 8 статьяның 1 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат эшчәнлеге рәвешләре булып:

1) җирлек Советы сессияләре эшендә катнашу;

2) җирлек Советының даими комиссияләре эшендә катнашу;

3) федераль дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына, барлык оештыру-хокукый рәвештәге оешма җитәкчеләренә, иҗтимагый берләшмәләргә мөрәҗәгать;

4) муниципаль хокукый акт проектын кертү;

5) җирлек Советы тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актлар проектларын эшләүдә катнашу;

6) җирлек Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертелә торган Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләүдә катнашу;

7) депутат гарызнамәсе кертү;

8) сайлаучылар белән очрашулар, аларның мөрәҗәгатьләре белән эшләү, үзе вәкил булган җирлек халкына үз эшчәнлеге һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү;

9) җирле референдумнарны, гавами тыңлауларны, җыелышларны, конференцияләрне һәм гражданнардан сорашып белешүләрне оештыруда һәм уздыруда катнашу;

10) территориаль иҗтимагый үзидарә оештыруда катнашу.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1йорт (җирлек администрациясе бинасы), Карәшәм авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Рус Әҗиле авыл җирлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы, Совет рәисе** **И.Р.Касимов**